МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кремлевская, д.9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль ур., 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

____________________№________________

На №__________ ______от________________

Руководителям отделов
(управлений) образования
Исполнительных комитетов
муниципальных образований
Республики Татарстан

О проведении III республиканской научно-исследовательской конференции «Туган телем – шагыйрьләр теле»

В целях привлечения учащихся к исследовательской работе, приобщения к духовным ценностям, традициям национальной культуры, выявления одаренных, талантливых детей Министерством образования и науки Республики Татарстан совместно с Институтом филологии и межкультурной коммуникации при Казанском федеральном университете, Управлением образования Исполнительного комитета Актанышского муниципального района, Государственным автономным общеобразовательным учреждением «Гуманитарная гимназия-интернат для одаренных детей» **5 декабря 2015 года** проводится III республиканская научно-исследовательская конференция школьников **«Туган телем – шагыйрьләр теле»** (далее — Конференция). На Конференцию приглашаются учащиеся VII-XI классов общеобразовательных организаций.

Для участия в Конференции необходимо **до 20 ноября 2015 года** направить заявку и материалы по электронной почте: venerahaeva@yandex.ru с пометкой «Конференция» с указанием фамилии автора.

Командировочные расходы производятся за счет направляющей стороны.

Ответственность за жизнь и здоровье школьников в пути следования и во время мероприятия необходимо возложить на сопровождающих педагогов.

Место проведения Конференции: 423740, Республика Татарстан, с. Актаныш, ул. Аэропортовская, д. 3а.

Телефоны для справок: 8(85552) 3-26-05 (секретарь); 89172573988 – заместитель директора по инновационной деятельности Хаева-Хаметзянова Венера Хаматнасыховна.

Приложение: на 5 л. в 1 экз.

**Заместитель Премьер-министра**
**Республики Татарстан – министр** **Э.Н. Фаттахов**

А.С. Шарипова,
8(843)294-95-09



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Укучылар өчен III республика **« ТУГАН ТЕЛЕМ – ШАГЫЙРЬЛӘР ТЕЛЕ»**
фәнни-эзләнү конференциясен үткәрү турында
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми мәгълүмат

1.1. Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан (Идел буе) федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе, «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автономияле гомумбелем учреждениесе белән берлектә күренекле язучы, Мөхәммәт Мирза иҗатына багышланган республика фәнни-тикшеренү конференциясен үткәрә. Конференциядә татар халкының мәгарифе, әдәбияты, мәдәнияте үсешенә зур өлеш керткән Габдулла Тукай премия лауреаты, җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәт Мирза тормышы һәм иҗади эшчәнлеге төрле юнәлешләрдә өйрәнелә һәм тикшерелә.

## 2.Конференциянең максат һәм бурычлары

Конференциянең максаты – эзләнү эшчәнлеге аша укучыларның иҗади фикер йөртүләрен, интеллектуаль сәләтләрен активлаштыру.
Конференциянең төп бурычлары:

- хәзерге заман укучысының гомуми һәм коммуникатив культура дәрәҗәсен, социаль активлыгын үстерү һәм җәмгыятьтә үз урынын табарга өйрәтү;
- укучыларда фәнни-эзләнү эше күнекмәләрен формалаштыру;
- бүгенге көн укучысының әдәп-әхлак идеалларын билгеләү;
- укучыларда телебезгә, милли гореф-гадәтләребезгә, рухи байлыгыбызга мәхәббәт тәрбияләү;
- фәнни-тикшеренү эше алып баручы коллективлар белән иҗади багланышлар формалаштыру, үзара аралашу оештыру;
- милли үзаң, үз милләтеңнең тарихына, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияләү;
- сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру.

## 3. Катнашучылар

III республика **«ТУГАН ТЕЛЕМ – ШАГЫЙРЬЛӘР ТЕЛЕ»** фәнни-тикшеренү конференциясе эшендә 7-11 сыйныф укучылары катнаша ала. Эшләр мөстәкыйль эшләнгән, мәгълүматлар анализланган һәм аларда авторның үз карашы, фикере чагылырга тиеш.

## 4. Бәйгене оештыручылар

- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы.
- Казан федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты.
- Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе.
- «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автономияле гомумбелем учреждениесе.

## 5. Конференцияне оештыру һәм үткәрү тәртибе

5.1. Конференция ике этапта үткәрелә.

**I этап** – әзерлек этабы

**II этап** – төп этап.

Әзерлек этабы – гаризаларны кабул итү – **2015 елның 20 ноябренә кадәр**. Килгән эшләрне оештыру комитеты составына кергән экспертлар тикшергәннән соң, икенче турда катнашучылар исемлеге 27 нче ноябрь көнне гимназиянең официаль сайтына куела.

Төп этап. Эшләр жюри тарафыннан тикшерелә һәм бәяләнә, таләпләргә туры килгән эшләрнең авторларына конференциягә катнашу өчен чакыру җибәрелә. Икенче турга узган укучылар 5 декабрь сәгать 9 га «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автономияле гомумбелем учреждениесенә «ТУГАН ТЕЛЕМ – ШАГЫЙРЬЛӘР ТЕЛЕ» фәнни-эзләнү конференциясенең финалына чакырыла. Эшләренең кәгазь варианты чыгыш ясар алдыннан экспертлар комиссиясенә тапшырыла.

5.2. «ТУГАН ТЕЛЕМ – ШАГЫЙРЬЛӘР ТЕЛЕ» фәнни-эзләнү конференциясе кысаларында түбәндәге секцияләр эшләячәк:

- **Мөхәммәт Мирза шигырьләрендә: заман һәм шәхес.**
- **Мөхәммәт Мирза шигырьләрендә шәхес язмышы һәм бүгенге җәмгыять;**
- **Мөхәммәт Мирза шигырьләрендә милли мәсьәлә һәм халык язмышы;**
- **Мөхәммәт Мирза шигырьләрендә тел һәм стиль үзенчәлекләре;**
- **Мөхәммәт Мирза иҗатының тәрбияви әһәмияте;**
- **Мөхәммәт Мирза иҗатын өйрәнү юнәлешендәге иҗади проектлар, презентацияләр.**

(Оештыру комитеты конференциядә катнашу өчен гаризаларны сайлап алу хокукын үзендә калдыра. Конференция әзерләү барышында үзгәрешләр һәм юнәлешләрне берләштерү булырга мөмкин).

5.3. Конференциядә катнашу өчен, **2015 елның 20 ноябренә** кадәр venerahaeva@yandex.ru электрон адресына гариза (заявка), доклад материаллары (10 биткә кадәр) җибәрелергә тиеш.

5.4. Һәр катнашучыдан билгеләнгән үрнәк буенча персональ мәгълүматларны куллануга ризалык турында белешмә тапшыру таләп ителә (Кушымта-Приложение).

## 6. Чыгышларга регламент һәм бәяләү критерийлар

6.1. Казан Идел буе федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты мөгаллимнәре, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе методистлары, Актаныш муниципаль районының югары квалификацион категорияле укытучыларыннан торган экспертлар комиссиясе укучыларның фәнни эшләренә, чыгышларына түбәндәге критерийлардан чыгып бәя бирә:

- билгеле булган фәнни фактларны куллану;

- сөйләмнең аңлаешлы булуы, кыскалык һәм ачыклык, күргәзмәлелек;
- аудитория белән элемтә;
- оригинальлек, заманчалык һәм чыгыш барышында цифрлы белем бирү ресурсларын нәтиҗәле куллану.

6.2. Секцияләрдә чыгыш ясауга 5-7 минут вакыт бирелә.
6.3. Фәнни-методик эшнең киләсе бизәлеше: формат – А4, бит параметрлары: кырыйлар – өске һәм аскы – 2 см, сул – 3 см, уң – 1,5 см, форматлаштыру бит киңлеге буенча, юл ара интервал –1,5, шрифт зурлыгы – 14. Кырларның контурлары куелмый. Эшнең исеме калын шрифт белән уртага языла. Доклад исеме астында бер интервал аша уртага юл хәрефләре белән авторның фамилиясе күрсәтелә. Инициаллар фамилия алдында күрсәтелә. Әгәр дә авторлар берничә икән, фамилияләр бер юлга языла. Алдагы юлда кыскартуларсыз оешма атамасы күрсәтелә.
6.4. Оештыручылар эшләрне түбәндәге очракта кире кага ала:

- авторлык буенча шикләр уянса;
- күрсәтелгән вакыттан соңрак тапшырылса;
- РФ һәм ТР кануннарына каршы килсә;
- педагогик укуларның тематикасына туры килмәсә;
- бизәлеш тәртипләрен үтәмичә башкарылган булса;
- логик, стилистик, орфографик һәм пунктуацион хаталар булса.

## 7. Нәтиҗә чыгару һәм җиңүчеләрне бүләкләү

Укучыларның фәнни эшләренә, чыгышларына эксперт комиссиясе югарыдагы критерийлардан чыгып бәя бирә. Чыгышлар тыңланып беткәннән соң һәр секциядәге экспертлар комиссиясе нәтиҗә чыгара, җиңүчеләрне билгели. Карарлар беркетмәгә теркәлә, үзгәрешсез кабул ителә.
2 нче турда җиңгән укучыларга дипломнар тапшырыла.

**Белешмәләр өчен адреслар һәм телефоннар:**
Электрон почта адресы: venerahaeva@yandex.ru
423740, Татарстан Республикасы, Актаныш авылы, Аэропортовская ур., 3а
Телефон: 8 (85552) 3-26-05
89172573988 (инновацион эшчәнлек буенча директор урынбасары Венера Нәсиховна Хәева-Хәмитҗанова)

## III республика « ТУГАН ТЕЛЕМ – ШАГЫЙРЬЛӘР ТЕЛЕ» фәнни-эзләнү конференциясендә катнашу өчен гариза

| | |
|---|---|
| Эшнең темасы | |
| Секция | |
| Авторның фамилиясе, исеме, (тулы килеш, татар телендә)<br>Фәнни җитәкчесенең фамилиясе, исеме,әтисенең исеме (тулы килеш, | |

| | |
|---|---|
| татар телендә) | |
| Оешма (устав буенча)<br>(адрес һәм телефон) | |
| Катнашучының телефоны | |
| Чыгыш өчен кирәк булган техник чаралар | |

Оешма җитәкчесенең имзасы

«________» _________________________________ 2015 ел.

Приложение

**Согласие на обработку персональных данных**

**Я,________________________________________________________________________,**

*(ФИО родителя или законного представителя)*

паспорт _____ ____________, выдан________________________________________

*(серия, номер)* *(когда, кем)*

___________________________________________________________________________

*(в случае опекунства / попечительства указать реквизиты документа, на основании которого осуществляется опека или попечительство)*

___________________________________________________________________________

*(адрес)*

даю согласие на обработку персональных данных моего ребенка

___________________________________________________________________________

*(фамилия, имя, отчество ребенка)*

паспорт _____ _____________, выдан _______________________________________

*(серия, номер)* *(когда, кем)*

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

*(адрес)*

оператору Министерства образования и науки Республики Татарстан для участия в конференции.

Перечень персональных данных, на обработку которых дается согласие: фамилия, имя, отчество, школа, класс, домашний адрес, дата рождения, телефон, адрес электронной почты, результаты участия в заключительном этапе конференции.

Оператор имеет право на сбор, систематизацию, накопление, хранение, уточнение, использование, передачу персональных данных третьим лицам - образовательным организациям, органам управления образованием районов (городов), Министерству образования и науки РТ, Министерству образования РФ, иным юридическим и физическим лицам, отвечающим за организацию и проведение различных этапов конференции, обезличивание, блокирование, уничтожение персональных данных.

Данным заявлением разрешаю считать общедоступными, в том числе выставлять в сети Интернет, следующие персональные данные моего ребенка: фамилия, имя, класс, школа, результат заключительного этапа конференции, а также публикацию в открытом доступе сканированной копии работы.

Обработка персональных данных осуществляется в соответствии с нормами Федерального закона Российской Федерации от 27 июля 2006 года № 152-ФЗ «О персональных данных».

Данное Согласие вступает в силу со дня его подписания и действует в течение 3-х лет.

_______________________ _______________________

(личная подпись) (дата)

Лист согласования к документу № 11198/15 от 04.09.2015
Инициатор согласования: Исмагилова А.Р. Ведущий консультант отдела национального образования
Согласование инициировано: 04.09.2015 16:30

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | | Согласовано 04.09.2015 - 17:53 | - |
| 2 | Ахметзянова Л.М. | | Согласовано 04.09.2015 - 20:16 | - |
| 3 | Мухаметов И.Р. | | Согласовано 04.09.2015 - 23:22 | - |
| 4 | Фаттахов Э.Н. | | Подписано 05.09.2015 - 05:52 | - |